РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 09 » 08 2024 ел № 797

Күпбалалы гаилә статусын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында»гы 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 санлы Указы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күп балалы гаилә статусын билгеләү турында»гы 2024 елның 18 июнендәге 20-09/8480 санлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары бирү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы мәгариф оешмаларында муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә, күпбалалы гаиләләргә ташламалар бирелгәндә, федераль дәрәҗәдә бердәм таныклык үрнәге билгеләнгәнче, балалар туу турындагы таныклык яисә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аны озайту һәм алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын билгеләү турында"гы 2012 елның 31 июлендәге 612 санлы боерыгы белән расланган күпбалалы гаилә

статусын билгеләү турында карар нигезендә ташламалар һәм хезмәтләр күрсәтергә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.А. Абрамов
тел. 2-42-23